РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

Исполнительный комитет
Аксубаевского
муниципального района

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

Аксубай муниципаль
районы башкарма
комитеты

ПОСТАНОВЛЕНИЕ

КАРАР

« 29 » 06 2020

№ 434

Аксубаево

Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Башкарма комитетының «Аксубай муниципаль районының муниципаль бюджет мәгариф учреждениеләрендә балаларны караган һәм тәрбияләгән өчен ата-ана түләвен тоту тәртибе турында»гы 05.08.2019 ел, №505 карары белән расланган Аксубай муниципаль районында мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы муниципаль белем бирү учреждениеләрендә ата-ана түләвен тоту Тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә һәм Татарстан Республикасы Аксубай районы прокуратурасының 02.06.2020 ел, 02-08-20 номерлы таләпләрен үтәү йөзеннән, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Башкарма комитетының «Аксубай муниципаль районы муниципаль бюджет мәгариф учреждениеләрендә балаларны караган һәм тәрбияләгән өчен ата-аналар түләвен тоту тәртибе турында» 05.08.2019 ел., №505 карары белән расланган Аксубай муниципаль районында мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы муниципаль мәгариф учреждениеләрендә ата-аналар түләвен тоту Тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә.

1.1. 2.3 п. 9 абзацында «һәм башка чыгымнар» сүзләрен төшереп калдырырга;

1.2. 2.3 п. 13 абзацын төшереп калдырырга.

2. Аксубай муниципаль районы Башкарма комитетының «Мәгариф бүлеге» муниципаль казна учреждениесенә (С.Ю. Зайцев) эштә куллану өчен ведомство карамагындагы учреждениеләр җитәкчеләренә җиткерергә.

3. Муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләре җитәкчеләренә, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып, Аксубай муниципаль районы Башкарма комитетының «Мәгариф бүлеге» муниципаль бюджет учреждениесенә ата-аналар түләве акчаларын тоту турында хисап бирүне тәэмин итәргә.

4. Әлеге карарны Аксубай муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга: http://aksubayevo.tatarstan.ru һәм хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Аксубай муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасарына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Аксубай муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе: А.Ф. Горбунов